«Артыгын сорамадым, тиешлесен Ходай бирде»

Балалар өчен язылган шигырь, хикәяләре рус, инглиз, әзәрбайҗан, чуаш, төрек телләренә тәрҗемә ителгән; төрле илләрдә 15 китабы дөнья күргән шагыйрә Йолдыз Шәрапова үзенең укучылары белән очрашулары вакытында иң еш кабатлана торган сорауларның берсе «Йолдыз булу кыенмы?»дыр, мөгаен. «Минем исемем генә Йолдыз!» – дип җаваплый аларны шагыйрә күп вакыт.

5 БИТ

Корылтай алдыннан: Казанда ассириялеләр тормышы

«1918 елда Казанга 40 ассирия гаиләсе килеп яши башлый. Белемнәре булмау сәбәпле, аларга аяк киемнәре төзәтү һәм чистарту эшләрен бирәләр. Хәзерге вакытта Татарстанда 126 ассирия милләте вәкиле яши. Без бирердә башка халыклар белән тигез хокуклы. Халыклар ассамблеясы советына кердек», – ди Казандагы ассириялеләр оешмасы җитәкчесе Арсен Савва.

4 БИТ

1990 ЕЛДАН БИРЛЕ ЧЫГА

Шәһри КАЗАН

татмедиа

Сишәмбе | 11.04.2017 | №38 (5800)

www.shahrikazan.com

ТАТАРСТАН БАШКАЛАСЫНЫҢ КӨНДӘЛЕК ИҖТИМАГЫЙ-СӘЯСИ ҺӘМ МӘДӘНИ ГАЗЕТАСЫ

«САЛАВАТ КҮПЕРЕ»НДӘ ӨЙ ТУЕ

Ниһаять, күпләр түземсезләнеп көткән «Салават күпере» торак комплексындагы 13-1 йортында төзелеш эшләре тәмам. Иртәгә, 12 апрель көнне, социаль ипотека программасы буенча әлеге йорттан торак отучыларга фатир ачкычлары тапшырылачак. Сентябрьгә кадәр комплекстагы барлык йортларда да өй туйлары гөрләр, дип ышандыра җитәкчеләр. Йортларның әзерлек дәрәҗәләре турында Татарстанның төзелеш, архитектура һәм торак-коммуналь хуҗалыгы министры урынбасары Илшат Гыймаев «Татар-информ»да узган матбугат конференциясендә сөйләде.

Эльвира МОЗАФФАР

Осиново бистәсе тирәсендә салынып килгән «Салават күпере» торак комплексындагы кайбер йортлар инде узган ел ук тапшырылырга тиеш булсалар да, кайбер сәбәпләр аркасында, гел кичектерелделәр. Ел башында Татарстан Президенты Рөстәм Миңнеханов үзе дә комплекста булып, бернечә кварталдагы төзелеш эшләренең барышы белән танышкан иде. Ул төзелеш оешмаларына эшне тизләтергә кушып, комплекстагы барлык йортларны да 15 сентябрьгә кадәр куллануга тапшыру бурычын куйды.

– Йортлар вакытында тапшырылыр дип уйлыйм. Бәлки кайбер торакларның төзелеп беткәнен озаграк көтәргә туры килгәндер, әмма монда сыйфатка зур игътибар бирелә, фатир хуҗалары күрсәткән барлык кимчелекләрне бетермичә, бер генә йорт та куллануга тапшырылмаячак, – ди Илшат Гыймаев.

Күпләр, обойлар купкан, стеналар чатнаган, ишекләр ябылмый, дип зарлана. 10-5 йортында хәзер нәкъ менә кимчелекләрне төзәтү белән шөгыльләнәләр. Апрельдә бу йорттагы фатирлардан да ачкычлар тапшырырга җыеналар. Аннан соңгы чираттагы йортлар – 10-7, 10-2. Аларга җылылык җибәрелгән, фасад өлешен төзекләндерү эшләре төгәлләнеп килә. Бу йортлар май азагына кадәр ишекләрен ачар дип ниятләнелә.

– 11нче кварталда төзелеш темплары акрынрак барса да, йортларның куллануга вакытында тапшырылуында шик юк. 11-4 йорты июнь аенда ук әзер булыр дигән өмет бар, – ди Илшат Гыймаев.

Бүген төзелеш мәйданчыгында дүрт подрядчы оешма эшли. Эшчеләрнең саны ике меңнән артып китә. Тиздән якын арада куллануга тапшырылачак йортларның ишегалларын рәткә китерү белән шөгыльләнәчәкләр: эскәмияләр куелачак, газон җәеләчәк, тротуарлар төзекләндереләчәк. Матбугат конференциясендә парковка мәсьәләсе белән дә кызыксындылар.

– Йорт ишегалларында парковкалар бар. Әлегә анда зур кырда да машина кую урыннары җитәрлек. Киләчәктә күп катлы парковка булдыру фикере дә бар. Моның белән бәлки инвесторлар шөгыльләнер. Әмма монысы инде башка мәсьәлә. Безнең беренче бурыч – кешеләрне фатирлы итү. Мәктәпләр, балалар бакчалары булдыру, – ди Илшат Гыймаев.

Мәктәпләр дигәннән, апрель аеннан «Салават күпере» комплексында 1224 балага исәпләнгән белем бирү йорты төзи башларга җыеналар. Мәктәп 2018 елда ачылыр дип көтелә. Ә менә балалар бакчаларына кытлык сизелми. Бүген комплекста эшләп килүче ике бакчада буш урыннар да бар әле. Дөрес, яшәүчеләр саны арткан саен, балалар да күбәер. Тик борчылыр урын юк, йортларның беренче катларындагы буш биналар балалар бакчасы өчен каралган.

Кыскасы, «Салават күпере» киләчәктә меңләгән халкы, үз мәктәбе, фельдшерлык пунктлары, административ үзәге булган шәһәргә әйләнер кебек. Август аеннан бирердә йортлар күпләп тапшырылыр дип көтелә. Тиздән Казанга килү өчен яңа автобус маршрутлары булдыру мәсьәләсе дә хәл ителәчәк.

– Әлегә «Салават күпере»ндә яшәү өчен бар уңайлыклар бәлки тудырылып та бетмәгәндер: төзелеш, тавыш. Әмма тиздән барысы да җайга салыныр.Үз фатирыңнан канәгать булып яшәү бик мөһим, – ди Илшат Гыймаев.

ГЕНЕРАЛЬ ПЛАН

«Салават күпере»нә трамвайда барачакбыз

Казанның Киров районы Урман аръягы бистәсендәге «Салават күпере» торак комплексына, мөгаен, киләсе елдан трамвайлар йөри башлаячак.

kazanfirst.ru

Дамир БӘДРИЕВ

– Татарстан Президенты йөкләмәсе нигезендә, «Салават күпере» комплексында торак йортларны файдалануга тапшыру активлашты. Нәтиҗәдә, анда халык саны кискен артачак. Ел ахырында Авиатөзелеш районындагы ТЭЦ урамыннан «Салават күпере»нә таба трамвай юлы сузуга карешеләчәк. Метро юлы төзү дә каралган, ләкин анысы – алдагы елларга исәпләнелгән эш, – диде архитектура һәм шәһәр төзелеше идарәсе җитәкчесе Владимир Фомин. – Горький шоссесына янәшә «Салават күпере» торак комплексына автотрасса да төзеләчәк.

Казанның 2035 елга кадәрге чорга исәпләнелгән Генераль планы әзерләнә. Проектта гомуми озынлыкта 354 чакрым юллар һәм тагын уннан артык урында юл-транспорт чишелеше (күпер) төзү күзаллана. Башкаланың «Зур боҗра» юлын төзү дәвам итәчәк. Казан эчендә электричка «боҗра» маршрутта хәрәкәтләнәчәк.

Шәһәрнең тарихи үзәгендә Татарстан Мәдәният министрлыгы рөхсәт биргән очракта гына нинди дә булса төзелеш эшләре башкарырга мөмкин. Федераль закон буенча, Казан Кремленнән Дәрвишләр бистәсенә кадәрге территорияләр «аеруча саклаулы» исемлегенә кертелгән. Төзелешләрнең һәм хәтта шәхси торак төзелеше документларын, төзелеш план-сызымнарын Мәдәният министрлыгында раслатырга кирәк булган. Мондый «киртә» сәбәбендә, быел шәһәр үзәгендә бер генә төзелеш тә башлангыч алмаган. Хәзер исә таләпләр сизелерлек үзгәртелгән.

– Казанның тарихи өлеше якынча 23,5 мең квадрат километрны тәшкил итә. Аның чикләре мәдәни мирас корылмалары күпләп урнашкан урыннарны колачлап уза. Тарихи җирлеккә: Казанның үзәгеннән Вишневский урамына, шулай ук Ершов урамыннан Октябрь шәһәрчегенә кадәрге җирләр, Киров районының бер өлеше һәм тулысы белән Адмиралтия бистәсе керә, – диде Владимир Фомин «эшлекле дүшәмбе» киңәшмәсендә.

Тарихи җирлектә борынгы корылмалар гына түгел, ә табигать ландшафты (тау, ерганак, агачлык, елга, күл) һәм җирнең археологик катламы да мәдәни мирас санала. Тарихи җирлектә үз белдегеңдә казырга-туздырырга рөхсәт юк.

Проблемалы йортлар – контрольдә

Татарстан Президенты Рөстәм Миңнеханов йөкләмәсе буенча, Татарстан премьер-министры вазифаларын вакытлыча башкаручы Алексей Песошин җитәкчелегендә даими эшли торган хөкүмәт комиссиясе төзелде. Казанда, Чаллыда һәм республиканың башка шәһәрләрендә проблемалы йортлар төзелешен төгәлләү буенча максатчан һәм планлы эш бара.

Казанда Чистай урамындагы 71а йорты төзелеп бетте. «Акварель» торак комплексының 5нче йортында 402 фатир хуҗасы якын арада ачкычларын алачак.

Татарстан Президенты әлеге мәсьәләне даими контрольдә тота. Комиссия һәр йорт буенча җитешсезлекләрне ачыклый һәм финанс чыганагы эзләү белән мәшгуль. Проблемалы йортны «Свей» активларын гамәлгә кертеп төзеп бетерү мөмкин булды.

Президент – Калифорниядә

Татарстан Президенты Рөстәм Миңнеханов Американың Калифорния штатында эшлекле сәфәрдә. Матбугат хезмәте хәбәр итүенчә, Татарстан делегациясе вәкилләре Калифорния губернаторы Джерри Браун белән очрашкан. Сәфәр кысаларында, Рөстәм Миңнеханов эшлекле киңәшмә уздырган. Анда Татарстан һәм Калифорния штаты арасындагы хезмәттәшлекне үстерү буенча чаралар каралган, икътисади-сәүдә, фәнни-техник, инвестицияләр һәм мәгариф өлкәсендәге элемтәләрне ныгытуга басым ясалган. Татарстан вәкилләре: мәгариф һәм фән министры Энгель Фәттахов, элемтә, мәгълүматлаштыру министры Роман Шәйхетдинов, сәламәтлек саклау министры Адел Вафин һәм башка җитәкчеләр Калифорниядәге әйдәп баручы бизнес-берлекләр белән очрашкан, штатның медицина инфраструктурасы, инжиниринг үзәкләре, фәнни-белем бирү оешмаларының тәҗрибәсен уртаклашкан.

ТАГЫН ЯНГЫН

Казанның Аракчино бистәсендә урнашкан барлык диннәр гыйбадәтханәсендә кичә янгын чыкты. Гадәттән тыш хәлләр бүлегенә ут чыгу хакындагы хәбәр 04:35 сәгатьтә килеп ирешә. Килгән янгын сүндерүчеләр ике катлы бинаның түбәсе януын күрә.

vk.com

Коткару хезмәте вәкилләре ишектәге кутсанлы йозакларны ватып бинага кергәнче, шактый вакыт сарыф ителә. Янгынны ике сәгать сүндергәннәр. Ут 200 квадрат метр мәйданга таралып өлгергән була, бинаның эчке өлешенә зур зыян килгән, дип җиткерә Россия Гадәттән тыш хәлләр министрлыгының Татарстан буенча баш идарәсе матбугат хезмәте. Коткару хезмәткәрләре бинаның икенче катында бер ир-атның үле гәүдәсенә юлыккан. Соңыннан билгеле булганча, ул элеккеге прораб – 63 яшьлек Мансур Зиннәтов булган, дип яза «Татар-информ».

Беренчел фаразлар буенча, барлык диннәр гыйбадәтханәсендәге янгын ут төртү аркасында килеп чыккан. Янгын сәбәпләрен тикшерүчеләр янгынга сәбәпче булган берничә урынны ачыклаган, янучан сыек матдә эзләре дә бар, диелә.

Янгын чыгарга берничә көн кала, Мансур Зиннәтов Казанның билгеле скульпторы Борис Зыковның кызы Евгения Чесноковага шалтыратып, әтисенең эшләрен алып чыгарга, аларны Константин Васильев музеена куярга кирәк дип әйткән. Бу турыда «Татар-информ»га Евгения Чеснокова үзе хәбәр иткән.

– Мансур миңа 5 апрель көнне шалтыратты, мине храмнан чыгаралар, дип әйтте. Әтиеңнең эшләрен чыгарырга кирәк. Мин барысы турында да сөйләштем, диде. Җомга көнне тагын шалтыратышып, төгәл вакытын сөйләштек. Скульптураларны шимбә иртән чыгардык. Алга таба нишләргә җыенасың дип сорагач, белмим, диде, – дип сөйләгән ул.

Барлык диннәр гыйбадәтханәсеннән Борис Зыковның 53 скульптурасы чыгарылган.

Гыйбадәтханәне төзүче Илдар Хановның бертуган энесе Илгиз Ханов та янгынның сәбәбе ут төртүдән дип фаразлый.

– Мин моны махсус ут төртү дип уйлыйм. Янаулар күптән булды, – дип белдергән ул «Татар-информ»га.

«Реальное время» онлайн-газетасы язганча, архитектор Илдар Ханов үлгәннән соң, гыйбадәтханәне аның энесе Илгиз Ханов белән Мансур Зиннәтов бүлешә алмаган. Юридик яктан аңа беркем дә хуҗа була алмый. Илдар Хановның бертуганы Флюра Галиева сүзләренчә, Зиннәтов законлы мирасчыларны беркайчан да эчкә үткәрмәгән һәм шартлатам дип янаган. Шуңа да кайберәүләр гыйбадәтханәгә Зиннәтов үзе ут төрткән дигән версияне алга сөрә. Әмма аңа мирас бүлүдә юридик ярдәм күрсәткән Роман Старов бу версия белән килешми. Аның сүзләренчә, прораб Зиннәтов храмны саклап калырга омтылган, аны саклап калу өчен ахырга кадәр көрәшкән. Ә менә бәхәсне берничек тә чишә алмаганнар.

Чүплектән арыныр чак

#ЭКОЯЗ2017

eco.tatarstan.ru

2016 елда республиканың Экология һәм табигый байлыклар министрлыгы тарихында өмәдә катнашучылар саны буенча рекорд куелган. Татарстанның миллионнан артык халкы табигатьне чүп өемнәреннән чистартырга чыккан. Полигоннарга 45 мең кубометр чүп ыргытылган. Республика буенча 600 мең төп агач һәм куак утыртылган. Экологлар быел да шул күрсәткечтән төшмәскә исәпли.

1 апрельдән Татарстанда #ЭКОвесна2017 санитар-экологик икеайлыгы башланып китте. Ун көн эчендә экологлар, республика халкы ярдәмендә, дистәләгән чүп урыннарын чистартуга иреште. Ләкин башкарасы эшләр буа буарлык әле.

БЕРЕНЧЕ НӘТИҖӘЛӘР

Татарстан экология һәм табигый байлыклар министры Фәрит Габделганиев сүзләренчә, санитар-экологик икеайлыкның беренче атнасында табигатьне саклау буенча 459 тәртип бозу ачыкланган, 288 протокол төзелгән, 21 предприятие һәм оешма, 63 вазифаи зат җаваплылыкка тартылган. 210 законсыз чүплек урыны ачыкланган.

Казанның Авангард урамы 91нче йорт тирәсен генә алыйк. Бирегә яшәүчеләр чүпне кая куярга дип артык азапланып тормаган, тәрәзәдән генә ыргыткан. Чүп пакетлары хәтта агачларда эленеп калган. Нәтиҗәдә йорт янәшәсендә генә зур чүп өеме җыелган. Хәзерге вакытта биредә тикшерү эшләре алып барыла. Экологлар килеп штраф белән янагач, җирле халык чүпне өмә ясап чистартырга сүз биргән.

3 апрель көнне Казанның сәнәгать предприятиеләре, төзелеш җирләре буенча Лаеш, Яшел Үзән, Биектау, Балык Бистәсе, Питрәч районнары территориясен һавадан тикшергәннәр. Нәтиҗәдә табигатькә зыян салучы 38 хокук бозу очрагы ачыкланган.

ХӘБӘР ИТ!

Быел төп игътибар — мәркәзебез Казанга. Татарстан башкаласының Конфедерация Кубогы кунакларын кабул итәсе бар бит әле. 2018 елда узачак Футбол буенча дөнья чемпионаты да тау артында түгел. Йөзгә кызыллык китерергә ярамый. Икеайлыкның беренче атнасында гына да Казанда 24 хокук бозу очрагы теркәлгән, ике юридик, ике урындагы, ике физик зат административ җаваплылыкка тартылган. Хокук бозу очраклары «Халык контроле», «Мәктәп экопатруле» порталлары, WhatsApp, Telegram каналлары, интернет, «кайнар элемтә» телефоны аша килеп ирешә. Инде 118 мөрәҗәгать килгән.

Законсыз чүп өемнәре «Татарстан Республикасының экологик картасы» системасына кертелә. Әлеге картаны онлайн режимда интернет челтәре аша күзәтеп була.

ЧИСТАРТ ҺӘМ БҮЛӘК АЛ

Әйләнә-тирәне чистартып, табигатькә файда ясап кына түгел, үзеңә бүләк отып та була әле. Яшьләрне табигатькә игътибарлырак булырга өндәү максатыннан, социаль челтәрләрдә #ЭКОвесна2017 конкурсы старт алды. Җиңүче iPad Air планшетына ия булачак. Бәйгедә катнашу өчен @MINISTERSTVO_ECOLOGIRT аккаунтына теркәлергә һәм үз инстаграм битеңдә капка төбе, парк, сквер, район, шәһәр территориясен җыештырган вакытта төшкән фотоңны #ЭКОвесна2017 хештегы белән урнаштырырга кирәк. Бүләкне инде 22 апрель көнне тапшырачаклар.

Шулай ук тиздән социаль челтәрләрдә #ЭКОвызовпринят дигән үзенчәлекле флешмоб башлана. Анда катнашу өчен, өмә вакытында төшкән фотоңны челтәргә куярга һәм #экоызовпринят, #ЭКОвесна2017 сүзләре язып, дусларыңны эстафетада катнашырга чакырырга кирәк. Шулай ук быел Экомәктәп, Экогаилә, Экопредприятие, Эковуз бәйгеләре булачак. Татарстан Республикасының «100 яшел почмагы» бәйгесе кысаларында актив балалар бакчалары һәм мәктәпләр, үз территориясен матурлау өчен, яшел үсентеләр алачак. Районнар да чисталыкта ярыша. Табылган һәм юкка чыгарылган чүп өемнәре, полигонга чыгарылган чүп күләме, макулатура һәм полиэтилен савытлар җыю, икеайлык дәвамында үткәрелгән чаралар ярдәмендә иң чиста муниципаль үзәкне билгеләячәкләр.

ЗАКОНСЫЗ ТАШЛАНГАН ЧҮП ӨЕМНӘРЕН КҮРСӘГЕЗ

(843)267-68-67 – телефонына шалтырата аласыз, мәгълүмат шулай ук **eco.signal@tatar.ru** почтасы, **+79872169779** номеры буенча WhatsApp һәм Telegram аша кабул ителә.

Татарстанда аюлар бар. Казан янәшәсендәге Раифа тыюлыгында инде мәчеләр өчен махсус парк төзеләчәк. Өйләребездә-урамнарда күреп гадәтләнгән дүрт аяклы кечкенә дусларыбызга түгел, ә Россия җирлегендә яшәүче мәче токымындагы кыргый җәнлекләр өчен булачак ул.

Казан янында – «Мәчеләр урманы»

ЭКОЛОГИЯ

Табигатьтән файдалану өлкәсенә күзәтчелек буенча федераль хезмәтнең коллегиясенең Иннополиста узган киңәйтелгән утырышында журналистларга җиткерелде бу яңалык.

– Россиядә, ә бәлки, дөньяда беренчеләрдән булып, кыргый мәчеләр өчен парк оештыру ниятебез бар. Мәчеләр иректә яшәячәк, кешеләр аларны килеп карый алачак, – диде Россия Федерациясе хөкүмәте рәисе урынбасары Александр Хлопонин.

– Әлеге паркны Казан янәшәсендәге Раифа тыюлыгында төзү турындагы тәкъдимебез Россия хөкүмәтендә теләктәшлек тапты, – дип, фикерне дәвам итте Татарстан Президенты Рөстәм Миңнеханов. – Барс – республикабыз символы. Аларны үрчетү үзәге төзеләчәк. Саяно-Шушенский тыюлыгы белән килешү кабул ителәчәк. Кар барслары соңыннан шул тыюлыкка җибәреләчәк, алар шундагы табигать мохитенә җайлашкан.

Коллегия утырышында ясаган чыгышында Александр Хлопонин Татарстанда табигатьне саклауга зур игътибар бирелүен мактап телгә алды.

– Яңа проектларны гамәлгә ашыруда Татарстан – гел беренче, пилот төбәк. Мәскәү белән бергәттән Казанда да чүп эшкәртү заводы төзелә. Халык борчылмасын. Чүп эшкәртүче бу завод бик камил, экологиягә зыян салмый, – дип ышандырды Александр Хлопонин.

Татарстан Президенты Рөстәм Миңнеханов чыгышында әйтелгәнчә, республикада ун елда 50 полигон төзелгән. Казанда көнкүреш калдыкларын урнаштыру мәсьәләсе аеруча четерекле. Самосыр полигоны инде тулган, шунлыктан биредә чүп кабул ителми.

– Рөхсәтсез урыннарда чүп өемнәре барлыкка китерелә. Казан янында чүп ягу-эшкәртү заводы төзелеше өчен Россия хөкүмәтенә рәхмәт! Бу бик тә зарури проект. Татарстанда быел – Сусаклагыч зоналарны үстерү елы. Идел ярларында 1200 чакрым ара тикшерелде инде. Яр буйларындагы экология таләпләрен бозучы 365 корылма сүттерелде. Экология әчтәлегендәге чаралар: сулыклар зоналарын, парклар һәм скверларны төзекләндерү дәвам итәчәк, – диде Рөстәм Миңнеханов.

Республикада җәмәгать транспортын һәм коммуналь тармак машиналарын газ ягулыгына көйләү программасы гамәлгә ашырыла. Президент искәртүенчә, республикада инде 5 мең машина газ ягулыгында эшли.

Россия Федерациясе Президентының Идел буе федераль округындагы вәкаләтле вәкиле урынбасары Олег Машковцев: «Идел буе федераль округында тупланган чүпләр хәзер 2 миллиард тоннаны тәшкил итә. Казанда 20 миллиард сумга чүп ягуэшкәртү заводы төзелә. Бу завод кискен мәсьәләне чишәргә ярдәм итәчәк», – диде.

Татарстан Президенты Рөстәм Миңнеханов экологиягә кагылышлы чаралар оештыруда Россиянең табигатьтән файдалануга күзәтчелек буенча федераль хезмәтнең зур ярдәм күрсәтүенә рәхмәт әйтеп үтте. Әлеге федераль хезмәтнең җитәкчесе республикада экология министры булып эшләп киткән Артем Сидоров икәнлеген дә истән чыгармыйк.

– Ил буенча 192 485 урында рөхсәтсез чүплек ачыкланды, шуның 134 845е бетерелде. Татарстанның экологияне саклау юнәлешендәге эшчәнлеге тәҗрибәсен Россиянең барлык төбәкләрендә кулланышка алу кирәк, – диде Россиянең табигатьтән файдалануга күзәтчелек федераль хезмәте җитәкчесе Артем Сидоров.

Дамир БӘДРИЕВ.

Автовокзалга бушлай автобуслар йөриячәк

«Казан-1» тимер юлы вокзалыннан «Южный» һәм «Восточный» автовокзалына бушлай автобуслар йөри башлаячак, дип хәбәр итә rbc.ru. Һәр юнәлеш буенча икешәр уңайлы микроавтобус йөрер дип көтелә. Маршрутлар расписаниесе поездның килү вакыты графигын күз уңында тотып эшләнгән.

Татарстанның Транспорт һәм юл хуҗалыгы министрлыгы мәгълүматлары буенча, гыйнвар-март аенда Горький тимер юлының Казан төбәге станцияләреннән шәһәр яны һәм ерак араларга 1,7 млн пассажир юл тоткан.

«Безнең милләт гомер буе газап чиккән»

КОРЫЛТАЙ АЛДЫННАН

Ассириялеләр – үз дәүләтләре булмаган милләтләрнең берсе. Алар элек Иранда, Төньяк Иракта, Сүриядә һәм Төркиядә яшәгәннәр. Бүгенге көндә дөнья буйлап таралганнар. Россиядә 20 меңнән артык ассирия кешесе гомер кичерә. Без Казандагы ассириялеләр оешмасы җитәкчесе Арсен Савва белән сөйләштек.

Люция ХӘБИБУЛЛИНА

– Арсен Владимирович, тарихтан да укып беләбез, ассириялеләр – күп михнәтләр чиккән халык. Милләт шулай булса да ничек сакланып калгансыз икән?

– Безнең милләт сугышлардан гомер буе газап чиккән. Православие динендә булганлыктан, әби-бабайларыбыз яшәгән мөселман илләрендә аларны бик каты кыерсытканнар. Шунлыктан башка илләргә күчеп китәргә мәҗбүр булганнар. 2013 елда Ирактагы канкойгыч сугышларда да безнең милләттәшләрне күпләп юк иттеләр. Балаларның башларын өзделәр, төрлечә җәзаладылар. Бу – безнең өчен зур фаҗига. Һәрвакыт бердәм булуыбыз милләтебезне саклап калырга ярдәм иткәндер дип уйлыйм.

– Әби-бабаларыгыз Казанга кайчан килеп урнашкан? Бүгенге көндә аларның гореф-гадәтләрен дәвам иттерәсезме?

– 1918 елда Казанга 40 ассирия гаиләсе килеп яши башлый. Белемнәре булмау сәбәпле, аларга аяк киемнәре төзәтү һәм чистарту эшләрен бирәләр. Хәзерге вакытта Татарстанда 126 ассирия милләте вәкиле яши. Без биредә башка халыклар белән тигез хокуклы. Халыклар ассамблеясы советына кердек.

Татарстанда аз санлы халыкларга игътибар зур.Үзебезнең бәйрәмнәрне бергәләп уздырабыз. 1 апрельдә Яңа ел бәйрәме (Хаб-Ниссан) үткәрдек. Гыйнварда һәм июньдә – Мар-Зайя, августта Мар-Нихал бәйрәмнәре уза. Пасхада бала-чаганың күкәй җыю йоласы бар. Сентябрьдә – Мар-Слыва, аннан соң дини бәйрәмнәребез үтә. Туйлар мондагыча уза. Элек кызларны үндүрт яшендә кияүгә алсалар, аның белән балигъ булгач кына яши башлаганнар.

– Сездә, кунак килгәндә, өстәлгә нинди ризыклар куела? Хатын-кызлар милли ризыкларны әзерлиме?

– Бездә күбесенчә көнчыгыш ашлары өстенлек итә. Милли ризыкларыбыздан дохва (иттән), катны ачыган сөттән әзерләнә. Чәй эчәргә яратабыз. Чәй янына хасыда дигән баллы ризык куела.

– Мәдәниятегезгә килгәндә...

– Җыр-биюләребез көнчыгыш халыкларыныкына охшаш. Халыклар дуслыгы йортында бию ансамблебез эшли. Анда халыкның элекке биюләрен өйрәнәләр. Халык җырларын да онытмыйбыз. Аларны туйларда җырлыйбыз.

– Милләттәшләрегез арасындагы танылган шәхесләрне дә беләсе килә.

– Татарстан гимнын русчага тәрҗемә иткән шагыйрь Филипп Пираев бәлки кайберәүләргә таныштыр. Мәскәүдә яшәгән галим, доктор, дәвалаучы Джуна Давиташвили безнең милләттәшебез иде.

– Хәзерге буынның туган телен оныта баруы куркытмыйммы? Бүгенге көндә ассириялеләр укырга, белемгә омтыламы? Үзегез кайда белем алдыгыз?

– Безнең туган телебез – рамен теле (симет телләре семьялыгына керә), Библия дә шул телдә язылган. Кызганыч, бүгенге көндә балаларыбыз туган телне онытып бара. Әгәр гаиләдә бала белән туган телендә аралашасың икән, ул аны онытмаска тиеш. Башка халыклардагы сыман, бездә дә катнаш гаиләләр барлыкка килде. Һәр ата-ана баласына югары белем алдырырга тырыша. Уку йортын тәмамлаучылар төрле оешмаларда хезмәт куя. Үзем Казан дәүләт федераль университетын, аннары аспирантура тәмамладым.

– Башка төбәкләрдә яшәгән милләттәшләрегез белән аралашасызмы?

– Безнең Мәскәүдә, Ростовта, Краснодар шәһәрләрендә җәмгыятьләребез бар. Анда чиркәүләр дә төзелгән. Алар белән форумнарда, конференцияләрдә аралашырга туры килә. Андагы милләттәшләр үз оешмаларында бары тик үз телебездә генә сөйләшә. 2011 елда Казанга Ирактан Епископ Мар Исхак Иосиф килде. Ул чакта Иракта чиркәүне шартлатканнар иде. Без аны Татарстандагы шартларны күрсәтү өчен чакырдык. Епископ биредә дин әһелләре белән очрашты. Казанда мөселманнарның ассириялеләргә карата мөнәсәбәтен күреп бик сөенде һәм гаҗәпләнеп китте. Аның: «Илдә шундый мөселманнар булганда, ассириялеләр тынычлап йоклый ала», – дигән сүзләре әле дә истән чыкмый. Соңыннан ул Президентка Рәхмәт хаты да юллады.

– Ассириялеләр оешмасында нинди эшләр белән шөгыльләнәсез?

– Ассириялеләрнең тарихы һәм мәдәнияте хакында «Бара» дигән бюллетень–журнал чыгарабыз. Бүгенге яшьләргә үткән тарихыбызны җиткерәсе килә. Милләттәшләр белән очрашып, аралашып торабыз. Бүгенге көндә без тынычлыкта, яхшы шартларда яшибез икән, Татарстан җитәкчеләренә рәхмәтле булырга тиеш.



ПОЧТАДАН

Җирдәге фәрештәләр

Яз көне күңел үсеп киткәндәй була, дөнья яктыра, тормышыбызда матурлык арта. Кояш та безне үсендереп елмаеп күз кыса. Буа районының Карлы авылында яшәүче Роза апа Гатауллина да язның һәр матур көненә бик сөенеп яши. Аеруча бу яз аның күңелендә тоташ сөенеч булып истә калыр.

Ник дигәндә, февраль аенда ул язмыш әзерләгән зур сынау белән күзгә-күз очраша һәм, Алланың рәхмәте белән, аны җиңеп чыга.

Үзе өшкерүче, баласызларны балалы итүдә күп көч куючы, авырып, сызланып килүчеләргә шифа биреп дәвалаучы Роза апаны Буада гына түгел, Татарстанда һәм хәтта Татарстаннан читтә дә бик күпләр белә, хөрмәт итә. Кыш ахырында Роза апага инфаркт була. Балалары, оныклары, туганнары һәм аның янына шифа эзләп зар елап килүче күпме кеше өчен борчу була бу хәл. Аны ашыгыч рәвештә Буа хастаханәсенең реанимация бүлегенә салалар. «Мине үлем тырнагыннан йолып алдылар, Буа район хастаханәсенең реанимация бүлегендә яңадан дөньяга кайтардылар», – дип, җан җылысы белән мактый ул үзен терелтүчеләрне. Чыннан да, Буа район хастаханәсенең табиблары могҗиза ясый. Алар көн дими, төн дими, һәр авыру гомере өчен шулай көрәшәләр, шуңа да терелеп чыккан һәр кеше аларны көн дә искә алып рәхмәтләр укый. Светлана Полянская, Наилә Гыйсмәтуллина, Евгений Одинцов, Марат Чагаев һәм анда эшләүче шәфкать туташлары бик зур мактау сүзләренә лаек. Әлбәттә, эшне дөрес оештыручы баш табиб Рөстәм Самерхановны аерып әйтергә кирәк.

– Әлеге табиблар гади генә кешеләр түгел, аларны Алла үзе сайлаган һәм кешеләргә ярдәм итәр өчен җиргә җибәргән. Мине һавадагы ак халатлы ак фәрештәләр коткарды. Буа хастаханәсендә эшләүче барлык табибларга, шәфкать туташларына һәм һәрвакыт янымда булучы улларыма һәм киленнәремә зур рәхмәтләремне газета битләре аша җиткерәм, – ди Роза апа Гатауллина.

Айсылу ИМАМИЕВА.

ТҮГӘРӘК

«Артыгын сорамадым, тиешлесен Ходай бирде»

Балалар өчен язылган шигырь, хикәяләре рус, инглиз, әзәрбайҗан, чуаш, төрек телләренә тәрҗемә ителгән; төрле илларда 15 китабы дөнья күргән шагыйрә Йолдыз Шәрапова үзенең укучылары белән очрашулары вакытында иң еш кабатлана торган сорауларның берсе «Йолдыз булу кыенмы?»дыр, мөгаен. «Минем исемем генә Йолдыз!» – дип җаваплый аларны шагыйрә күп вакыт.

Расиха ФӘИЗОВА

Шулаен шулай да, иллә мәгәр, Минненур ханым, моннан 55 ел элек бердәнбер кызына исем сайлаганда, исеме җисеменә туры килерлек, мәгънәле, язмышына йогынты ясарлык булсын дип әзләми калмагандыр. Юраган юш килә, диләрме? Шулай була да бит! Кызының балалар әдәбияты күгендәге якты бер йолдыз булып балкуын күреп, белеп китә әни кеше бу якты дөньядан. Ә моның өчен бөтен алшартлар да була: «Сабантуй»да Илдар Юзеев, Роберт Миңнуллиннар белән бергә эшләү дә, тәүге китабы – «Антенналы бәрәңге»се (1994 ел) чыккач, Шәүкәт абый Галиевтән аңа карата зур бәя алу да эзсез узмый. Җитмәсә, «Ел китабы» бәйгесендә икенче урын да нәкъ шушы китапка тәгаенләнә. Болар барысы да сабыйлар иленә, бала күңеленә илткән олы юлда үзе бер сынау, үзе бер мәктәп була. Аннан этисез үскән балачагы да күңелен бик иртә сизгер, шигъри җанлы итә кызның.

– Әти безне миңа бер ай да 13 көн булганда ташлап киткән. Шул китүдән аның безгә килгәне булмады. Гаилә таркалгач, әни кияүгә чыкканчы яшәгән фатир хуҗасы Мәкъбүлә әби янына киредән кайткан. Мәкъбүлә әби дә ялгыз – ире сугышта һәлак булган, бердәнбер баласын югалткан тома ятим карчык иде. Мине шушы ике тол аякка бастырды. Әни шушында – Яңа Тинчәледә (Буа районы) гомер буе математика укытты. Мәкъбүлә әби белән, әниле-кызлы кебек, 21 ел бергә яшәделәр. Аннан мин КФУга укырга кергәч, әни Казанга килде. Әниле чаклар тормышымның бик кадерле мизгелләре булган, әмма ул вакытларның кадерен генә белмәгәнбез икән... – ди Йолдыз ханым, хатирәләргә бирелеп.

Тик ул һич кенә дә язмышына үпкәләми. Ходай тагын бер гомер бирсә дә аны нәкъ менә шушы юлдан узачагына шиге юк.

– Дөрес, бер кулымнан әни җитәкләгәндә, икенче кулым буш кала торган иде, шуны күреп, Ходай ул кулыма каләм тоттырды. Әтием булмаганга бик кимсенеп үстем. Җиңел яшәмәдек. Язмышымнан артыгын сорамадым, тиешлесен Ходай үзе бирде. Әтинең мине калдырып китүен балачак акылым бервакытта да гафу итмәде, хәзергесе аңлады да, кичерде дә. Менә шушы күңел каршылыклары җанның иң нечкә кылларына кагылды да инде. Кияүгә чыкканчы, әти кирәк, дип бәргәләнде җаным... Ходайга шөкер, улларым: «Бабайны күрәсе килә», – диделәр... Әтинең үләренә бер ел кала – 53 елдан соң очраштык, бәхилләштек. Улларымны да алып бардым. Менә шушы гомер яшәп, чынга ашмаган бер генә хыялым да калмады бугай инде... – ди Йолдыз ханым, үзенчә бер нәтиҗәгә килеп.

Хәер, һәр чорның үз хыялы була анысы. Әйтик, әле кайчан гына бер-бер артлы дүрт ир бала тапкан Йолдыз җирән чәчле, зәңгәр күзле, сипкелле генә бер кыз турында хыялланган булган. Уллары Сәйдәш, Ядкәр, Айнур, Газиз дә сеңелләре булуны бик тели дә бит... «Тапкан очракта да, бишенчесе дә, иманым камил, малай булган булыр иде, чөнки әни яклап бабамнар җиде ир бала үскән. Аларның балалары да малайлар гына», – ди ул.

Бик теләгәч, кыз да бирә Ходай. 2007 елда, тәвәккәлләп, бер ятимне бәхетле итеп, Әдиләле булалар. Хәзер инде ул Сирин кызы Шарапова булуына, бер-берсен күз карашыннан аңлый торган, бер-берсенең кадерен белгән бәхетле, тулы гаиләгә эләгүенә сөенеп туя алмый. Иң мөһиме иркә, ягымлы, назлы кыз булуның ни икәнен белә бу бала.

...«Сабантуй»да ярты җаным калды, дия-дия, «Шәһри Казан»да эшли башлавына нибары ел да ике ай гына әле Йолдыз Шарапованың. Әмма монда да үз укучысын тиз тапты ул. Тәрбиягә бала алып үстерүче гаиләләр, ятимнәр, ишле балалы гаиләләр, аларны яклау, саклау – барысы да аныкылар. Бу теманы ишетеп кенә белүчеләрдән түгел шул Йолдыз.

Хәер, әле тагын бер бик тә татлы хыял яши Йолдызыбызның күңел түрендә: оныкларын алдына утыртып, аларга үзенең китапларын укыйсы, «Туган тел»ле итәсе бар әле аның.

ЙОЛДЫЗ

Дөнья ул – мин!

Явызлыкны күрә-күрә
Кысылдылар күзләрем.
Замананы сүгә-сүгә
Кырысланды сүзләрем.
Бик үзгәрдек. Ник үзгәрдек?
Әллә дөнья, әллә мин?
Җавабын төгәл белмим,
Күрәсең, дөнья ул – мин!

Хыял һәм чынбарлык

Хыял канатлы була,
Бал кебек татлы була,
Кояштай якты була.
Тик күп вакыт чынбарлык
Була көчкә чыдарлык...

Күбәләк

Мин – күбәләк,
Канатым бар,
Яши алмыйм очмасам.
Очам, очам,
Күкне кочам –
Шундый рәхәт, ичмасам.
Мин – күбәләк,
Очам, очам.
Кайчак түбән,
Кайчак биек.
Канатларым кояшка да
Китәдер әле тиеп.
Яңгыр асларында калып,
Кайчагында нык чыланып,
Кояшта кибенеп ятам.
Кабатланмасын иде дип,
Мондый да җуләр хатам.
Кайчак туңып, кайчак өшеп,
Кайчагында тирләп-пешеп.
Азга гына җиргә төшеп,
Тәмам хәлсезләнеп бетеп,
Җылы, матур көннәр көтеп
Яшим!
Тагын бераз хәл алам да
Күтәреләм күккә.
Ә биектә бөтен нәрсә
Әйләнә ул чүпкә.
Мин – күбәләк.
Очам, очам,
Яши алмыйм очмасам.
Сөенәмен, ярый әле
Оча беләм, ичмасам!
Очу – шатлык,
Күктә – ирек!
Күбәләк кенә булсам да,
Тоям кайчакта үземне
Горур бер бөркет диеп.
Бөркет тә шул ук күктә,
Шунда ук күбәләк тә.
Ләззәтле дә, газаплы да
Канаты бар йөрәккә...

Җан һәм Тән

Әллә чын, әллә уйнап
Баш әйтте: «Туйдым уйлап».
Күзем: «Туйдым елап», – ди.
Йөрәк: «Булмый чыдап», – ди.
Телем әйтә: «Туйдым, – ди, –
Ялган сүзләр сөйләп».
Колак әйтә: «Туйдым, – ди, –
Ишетеп нахак, гайбәт».
Аяк әйтте: «Юк артыннан
Туйдым йөреп, чабып».
Беркөн гәүдәм баш күтәрде:
«Бу дөньядан туйдым, –
диеп, – арып.
Рәхәтләнеп ял итәсем килә».
Күңелнең иң төпкелендә
Бер аваз ишетелә.
Әллә елый, әллә көлә
Җан икән, иңри мескенкәй:
– Минем яшисем килә!

Черки

Черки төтеннән дә курка,
Күбәләк утка килә,
Канатын өтсә дә килә,
Янып бетсә дә килә.
Син аны җуләр димә.
Гомер буе пыскыганчы,
Бер януга ни җитә?!
Бәләкәй генә күбәләк
Битараф җаннарны шулай
Гомерен биреп кисәтә.

Таң алды

Төн. Дөнья дөм караңгы
Күңелемне бераү какты,
Йокымнан уятты –
Илһам икән.
Хәл белергә килгән.
Икәү учак яктык,
Хисләр таштыы, акты,
Очты чаткы.
Ул чаткыдан
Җиһанга ут капты.
Инде дөнья якты,
Таң атты!

Йөрәккә

Явыз язмыш сакалыңнан
Йөретсә дә сөйрәп,
Йоткан уттан күлмәкләрең
Бетсәләр дә көйрәп,
Дус дигәнең танавыңа
Төртсә йодрык төйнәп,
Гайбәтчеләр гайбәтеңне
Төкерсәләр чәйнәп,
Хаксызлыктан кысылудан
Туктый язса йөрәк,
Сагыш суын чөмергәндә
Тутырып чиләк-чиләк,
Ялгышканда, адашканда
Көч беткәндә йөдәп,
Кеше булып калучылар
Бүген бигрәк сирәк.
Күңелемдә тик бер теләк:
Соң сулышка кадәр
Кеше булып калу юлын
Өйрәт миңа, йөрәк!

Күңелгә дәва алдык

Без – китап укып үскән балалар. Әниләрдән кача-поса укыдык китапны, авыл балалары булгач, укырга вакыт аз кала иде, мәктәптән кайтуга тау хәтле эш көтеп тора. Аннан дәрес әзерлисе, йокларга яткач кына эләгә китап уку. Инде китап эчендәге геройлар белән очрашып, шул дөньяга кереп кенә китәсең, йокыга киткәнеңне сизми дә каласың. Дәвамын төштә күрсәң генә инде.

Хәзер инде менә китаплар үз кулымда, мин – китапханәче, күпме телисең, шуның хәтле укырга була. Әшең китапханәче булгач, китапларны укып кына калмыйча, шул китапларны язган язучылар, шагыйрьләр яисә аларның якыннары, бергә эшләгән кешеләр белән очрашу бәхете дә тия безгә. Күптән түгел генә язучы якташыбыз педагог Азат Вергазовның тууына 85 ел тулуга багышланган искә алу кичәсе уздырдык. Кызганыч, Азат абый безнең арада юк инде, шулай булса да, кичәгә әзерләнгәндә аның гаиләсе – тормыш иптәше Разия апа, кызы Лилия, бертуган сеңлесе Фирдәүс апа белән танышырга насыйп булды. Азат абый Вергазовның үзе кебек олы җанлы, кешелекле, ярдәмчел, зарланмыйча, тормыштан канәгать булып яшәүче кешеләр алар. Беренче генә тапкыр күрсәк тә, шундый тәэсир калдырдылар безнең күңелдә. Кызы Лилия инвалид коляскасында дигәч, очрашу ничек булыр дип борчылыбрак кергән идек өйләренә – елмаеп каршы алды ул безне. Өстәлдә – бизәкләп эшләнгән шигырьләр китаплары. Мондый китапларны төзеп чыгарыр өчен нинди зур сәләт, түземлелек, тырышлык кирәк. Компьютердагы сайтын да «Мин яратам бу дөньяны» дип атаган ул. Бу тормышта үз урыннарын тапмаган саусәламәт яшьләргә үрнәк ул Лилия. Шигырьләре дә дөньяны яратып, оптимистик рухта язылган.

Разия апа Азат абый турында истәлекләр сөйләп алды, аның күзләренә Азат абыйны олылавы, сагынуы чыккан иде.

Фирдәүс апа белән китапханәбездә үткәрелгән кичәдә таныштык. Абыйсы турында шуның хәтле яратып, хөрмәтләп сөйләде, барыбыз да тын да алмый тыңладык аны. Фирдәүс апа белән Карауҗадан ветеран-укытучы Әлфия Минһаҗева да килгән иде. Ул залда утырган яшүсмерләргә Азат Вергазов әсәрләренең тормышның үзеннән алынып нәкъ менә алар, яшүсмерләр турында язылганлыгын сөйләде, һәм бу әсәрләрдән яшьләрнең үзләрен борчыган сорауларга җавап табып булуын әйтте. Азат Вергазов шигырьләренә көй иҗат иткән, Яшел Үзән шәһәре музыка мәктәбендә эшләүче укытучы Алсу Нәҗметдинованың пианинода үзе уйнап җырлавы, Азат Вергазов белән бергә гимназиядә эшләгән рәссам Вил абый Шәрәфетдиновның курайда уйнавы, укучыларның әдипнең шигырьләрен укулары кичәне тагын да эчтәлеклерәк итте. Менә шундый кичәләр, кичәгә килгән мөхтәрәм кешеләр белән очрашу балалар күңеленә кереп калыр, татар язучыларының иҗаты белән кызыксынуларын үстерер, матур әдәбиятка тартылуны арттырыр дип ышанып каласы килә.

Фәния ХӘКИМОВА,
Яшел Үзән шәһәренең 42нче номерлы милли төбәкне өйрәну китапханәсе китапханәчесе.

Балачак – иң бәхетле чак

Кеше гомере буе балачагын сагынып яши. Җае чыккан саен, хыялында гына булса да, яланаяклы шул самими чорга кайтып килә. Вакыт машинасының ачкычына ия шагыйрьләр бу балачак иленә бүтәннәргә караганда ешрак та кайта әле.

Шагыйрь, галим-укытучы, публицист Хәнәфи Бәдигыйның «Акыллы туп» исемле яңа китабы да шушы балачак-балчакны сагынып, шуны яратып, мактап язган шигырьләрдән тора. Иҗат иткәч тә башта ул аларны үзләренә атап язган балаларга укыган. Аннары шигырьләр республика балалар матбугатында дөнья күреп, күбрәк укучысын тапкач, инде автор махсус китап итеп бастырырга уйлаган. Бик дөрес эшләгән. Чөнки малайлар-кызлар өчен язылган китаплар бик аз нәшер ителә, бармак белән санарлык кына. Югыйсә, өлкәннәрнең киләчәк буынга әйтер сүзләре дә күп, уртаклашыр тәҗрибәләре дә шактый. Хәнәфи абый да әлеге яңа китабында үзенең бай тормыш тәҗрибәсеннән нәни дусларына өлеш чыгарырга алынган. Дөрес, төртеп, акыл өйрәтеп түгел (моны беркем дә яратмый), ә шигъри алым-калыпларга салып, шагыйранә хәйләләп. Педагог-шагыйрь моның өчен бөтен осталыгын, талантын җиккән. Теләге дә изге: киләчәк бүгенгедән матуррак, мәгънәлерәк булырга тиеш. Ә матур киләчәкне өлкәннәр сузен тыңламый, китап укымый, гомумән, рухи байлыксыз гына төзеп булмый. Дөрес, аларның хәзер фикерләре баш-

качарак, еш кына без өлкәннәрнеке белән туры да килми. Ләкин мәңгелек кыйммәтләр: намус, шәфкать, игелек, мәхәббәт бар бит әле.

Бу яңа китапны игътибар белән укып чыккан һәркем анда нәкъ менә үзенең балачагын күргәндәй булыр. Әйтерсең лә шагыйрь качып кына аның футбол уйный торган «Акыллы туб»ының капкага керүен карап торган, гөлләр үстерүче кызларга карап сокланган, «Июль иле»ндә бергәләп «Болытсыз яңгыр»да чыланган. Әйе, ул да, һәммәбез шикелле, җәйне, җиләкле июльне, балачакны ярата. Китабында Хәнәфи абзый шулай, иҗатында гына булса да, шук-шаян малайчагына кайткан һәм төрле кызыклар эзләп йөргән. Эзли торгач, таптапкан да. Алар әлеге җыентыкта шактый. Аны укыгач, бүгенге заман балалары бал чаклары нә җитдирәк карый башлар, аның мизгеленең дә кадерен белергә тырышыр, дип өметләнә шагыйрь-абый.

Йолдыз ШӘРАПОВА,
балалар шагыйрәсе.

КАЙТАВАЗ

Ялган

«Шәһри Казан» газетасының 7 апрель санында үзен академик дип белдергән Марсель Әхмәтҗановның «Бөек шагыйрь андый вак-төяк алдавычлардан югары» дигән тоташ ялган һәм хөсетлек белән сугарылган язмасы басылып чыкты. Дөрес, без моңа әллә ни артык гаҗәпләнмәдек. Чөнки мәзкүр авторның андый характердагы чыгышлары инде беренче мәртәбә генә түгел. Шуңа күрә бу очракта ул язмаса, гаҗәп булыр иде. Аның нәгърә ору рәвешендә язылган фикерләренә, дөресрәге, кизәнүгә җавап биреп тору кирәкмәс тә кебек иде. Чөнки безнең тарафтан төзелгән «Тукай – ядкярләрдә» исемле ике томлы хезмәт (гомуми бит саны 1688) Татарстан, Башкортстан, Төркия матбугатында объектив бәяләмәсен алды инде. Әмма академик (?) язмасының эчтәлеге җәмәгатьчелекне буташтыру-саташтыруга юнәлтелгән булу сәбәпле, үзебезнең фикерләребезне белдерүне кирәк таптык.

Беренчедән, язманың эчтәлегеннән күренгәнчә, академикның (?) «Тукай – ядкярләрдә» исемле хезмәт белән бөтенләй таныш түгеллеге ачыклана. Югыйсә, төзүче-авторлар арасында Рафис Исламов дигән кеше бөтенләй юк лабаса. Ул шулай ук, кереш мәкаләне генә укыган булса да, «Тукай шәхесе сәхифәләре битләрендә яңалык бармы икән соң?» – дип азапланмас иде.

Икенчедән, аның «Тукай мирасын өйрәнмичә генә, моңа хәтле басылып килгән хезмәтләрне яңадан бастырып чыгару…» дигән сүзләре дә дөреслеккә туры килми. Без бары тик беренчел чыганаклар белән генә эшләдек. Шуңа күрә дә ике томлыктагы 599 берәмлек материал хәзерге укучыга беренче мәртәбә тәкъдим ителде.

Өченчедән, академик (?) хезмәт белән турыдан-туры таныш булса, «Тукай шәхесен күтәрүдә оригиналь күренеш дип бәяләргә мөмкинме?» – дип, ниндидер аңлаешсыз сорау белән буталып утырмас иде.

Дүртенчедән, академик (?) безне «шагыйрь иҗатын һәм тормышын өйрәнүдә моңарчы кыл да кыймылдатмау»да гаепләргә тырыша. Димәк, ул көндәлек матбугат белән танышып бармый яки теләми булса кирәк. Чөнки ике томлык хезмәтебез басылып чыкканга кадәр үк «Мәдәни җомга», «Кызыл таң» газеталарында, «Безнең мирас», «Научный Татарстан», «Тулпар» журналларында Тукайның тормышына һәм иҗатына багышланган шактый мәкаләләребезне укыган булыр иде.

Академикның (?) Тукай хакында ике томлы хезмәтне «алдашып чыгару чарасы» дип атавын берниндри мантыйк белән аңлатып булмый, әлбәттә. Бәлки ул үз хезмәтләренең «фәнни дөреслеге» хакында Р. Мәрданов һәм И. Һадиев тарафыннан нәшер ителгән «Фәнни җаваплылык какшамасын! Филология фәннәре докторы Марсель Әхмәтҗановның «XVII-XVIII гасыр татар ташбилгеләре» (Казан, 2011. – 260 б.) китабындагы ялгышлар турында) (Казан, 2011) китапны күз алдында тотадыр.

Әгәр дә язма авторы көндәлек матбугат белән даими танышып барса, бу хезмәтне Г.Тукай исемендәге Дәүләт премиясенә тәкъдим иткән оешма турында «Кем соң моның инициаторы» дип «өзгәләнмәс» иде.

Искәрмә: Россия Федерациясе һәм Татарстан Республикасы Фәннәр академияләренең академиклар (хакыйкый әгъзалар) исемлегендә Марсель Әхмәтҗанов исеме табылмады.

Рәмил ИСЛАМОВ,
филология фәннәре докторы,
Җәүдәт МИҢНУЛЛИН,
тарих фәннәре кандидаты.

tatar-inform.ru

ФЕСТИВАЛЬ

Укуда да, иҗатта да алдынгылар

7 апрель көнне Казанның УНИКС концертлар залында «Язгы тамчы» республика фестиваленең гала-концерты узды. Фестиваль инде егерме беренче тапкыр Татарстан техникумнары һәм көллиятләренең иҗади яшьләрен җыя.

Быел ул 85 һөнәри белем бирү учреждениеләрен, шул исәптән 13 мең укучы студентны үз эченә колачлады. Казан, Чаллы, Түбән Кама, Әлмәт, Минзәлә, Чистай, Тәтеш шәһәрләрендә фестивальнең сигез зона этабы узды.

2017 ел — Экология елы булуы уңаеннан, фестивальнең темасы да «Безнең дөнья. Минем Җирем» шигаре астында узды. Һәр чыгыш табигать темасына багышланган иде.

–Татарстанда яшьләр, студентлар, балалар өчен үткәрелгән фестивальләр һәрвакыт ташып торган энергия алып килә. Сезнең һәрберегез һичшиксез уңышка ирешәчәк. Ышаныгыз, бу тормышта иҗат белән сәләт һәрвакыт кирәк булачак. Исегездә тотыгыз, сезнең идеяләрегез, эшегездән безнең республиканың, илнең киләчәге тора, – диде катнашучыларга Татарстан Республикасы Президенты ярдәмчесе Ләйлә Фазлыева.

– Фестиваль һөнәри белем бирүче уку йортларында бик зур иҗат потенциалы яшеренгәнен тагын бер кат дәлилли. Сезнең сәләтегез, мөмкинлекләрегез яшәү дәверендә һәрвакыт кирәк булачак. Быел фестивальдә Казан укучылары гына түгел, республиканың барлык районнарыннан килгән студентлар катнашуы сөендерә, – диде Татарстан Республикасының мәгариф һәм фән министры беренче урынбасары Андрей Поминов.

Бәйгенең фестиваль программасын әзерләү һәм театр юнәлеше буенча Гран-прины Казан педагогия көллияте алды. Музыкаль юнәлештә Тимирясов исемендәге Казан инновация университеты, хореография буенча — Әлмәт политехник техникумы, оригиналь жанр буенча Алабуга политехник көллияте шулай ук Гран-при иияләре булдылар.

«СӘЛӘТ» җәйге ялларга әзер

Балаларның җәйге ялына алдан әзерләнеп кую хәерле. Әнә «Сәләт» лагере узган елның көзеннән үк әзерләнә башлаган инде.

Алисә САБИРОВА

«Сәләт» республиканың барлык районнарына үтеп керде. Азнакай, Буа, Бөгелмә, Чаллы, Биектау районнарында быел да кызыклы сөрәннәр яңгыраячак. Алексеевск районындагы «Фәнсар» үзәгендә исә ел дәвамында дүртәр смена үткәрелә: «Сәләт-Осталар бистәсе», «Сәләт-Биләр каласы», «Сәләт-Санак», «Сәләт-Имәнкәй». Бу җәйдә «Сәләт» аланнарында 25 профильле сменалар эшләячәк, аларда 15 меңгә якын бала ял итәчәк.

Республикадан читтә яшәүче татар балалары да «сәлкеш» була ала. Самара өлкәсендә «Сәләт-Самара», Башкортстанның Туймазы районында «Сәләт-Кандракүл», Чувашия Республикасында «Сәләт-Батыр» аланнары эшли. Ә АКШ белән Канадада яшәүче татарлар «Сәләт-Монреаль» аланында татар теле белемнәрен шомартып, милли тәрбия ала.

Ел саен Биләр каласында шаулаган «Сәләт» форумы да быел, Татарстан Республикасы Президенты хәер-фатихасы белән, ике тапкыр узачак. Беренче смена дүртенче сәнәгать революциясе вакытында белем алуга юнәлтелгән. Бу форумда барлыгы 5000 кеше катнашыр дип көтелә. Икенче смена IT өлкәсе белән кызыксынучы 2500 кешене сыйдырачак. Форумның икенче өлеше мәгълүмати технологияләр, инновация, интеллектка багышланачак.

«Сәләт»тә ял итәргә теләүчеләр, инде февраль аеннан portfolio-selet.ru сайтында теркәлеп, гаризалар калдыра ала иде. Ә лагерьларның төрләре чиксез. «Сәләт-Раушан» аланын гына алыйк, бирегә иң сәләтле балалар гына сайлап алына. Башка аланнар белән чагыштырганда, татар телен белү мәҗбүри. Шулай ук төрле олимпиадаларда җиңү яулау да мәслихәт. Балалар ял итеп кенә калмый, ә иҗат, әдәбият, эшмәкәрлек нигезләренә дә төшенә. Хәтта төрле фәнни тәҗрибәләр дә ясый. «Сәләт-Осталар бистәсе» аланында сыерчык ояларын үз куллары белән ясап, орнитологларга кирәкле мәгълүмат туплаячаклар. Әйтик, ояга чип куеп, кошның көненә ничә тапкыр өйгә кайтуын санап чыгаралар. Хәтта үзе җыелына торган сыерчык оясы да ясыйлар икән.

vk.com

Кече бизнес популярлашып киткән заманда, балаларның да эшмәкәрлелек серләренә төшенәсе килә. Шул максатлардан «Сәләт-Эшмәкәр» аланы булдырылган. «Сәләт» фонды башкарма директоры Тимур Сөләйманов сүзләренчә, әлеге алан балаларны эшлеклелеккә, финанслау нигезенә төшенергә, идеяне тормышка ашырырга өйрәтә. Соңгы көндә балалар әти-әнисен ял дәверендә ирешкән уңышлары белән таныштырып, ярминкә оештыра.

«Сәләт» яшьләр үзәге директоры Айгөл Габдрахманова сүзләренчә, «Сәләт» ул – өч телле мохит.

– «Сәләт» – акыл, рух, тел берлеге. Бездә чараларның 50 проценттан артыгы татар телендә бара. Шуңа да тел белмәгән кешегә ияләшеп китү авыррак булырга мөмкин. Ләкин татар телен белү төп таләп түгел. Иң мөһиме – балада тел өйрәнергә теләк булсын. Минемчә, бүген Татарстанда яшәп тә татар телен өйрәнү мөмкинлеген кулдан ычкындыру – ахмаклык. Татар теле – теләсә кайсы төрек теленә ачкыч бит ул. Бездә татар телен үз теле кебек өйрәнгән кешеләр бик күп. Алена Быкованы гына алыйк, ул – рус кызы. «Сәләт»нең башка балалары белән бергә, ул Монреальгә барачак, – диде Айгөл Габдрахманова.

«Сәләт» аланнарына 5-11нче сыйныф балаларын кабул итәләр.

«Моны безнекеләр – арчалылар гына булдыра!»

Арча районы якташлыгы ике кич Кәрим Тинчурин исемендәге Татар дәүләт драма һәм комедия театры сәхнәсендә «Арчалар – ут күршеләр кунак җыя» дип исемләнгән зур концерт үткәрде.

Зөһрә САДЫЙКОВА

Анда Арча төбәгендә туып-үскән җырчылар – Нурзадә, Рөстәм Закиров, Габделфәт Сафин, Гөлзадә Сафиуллина, Фәрид Низамиев һәм башкалар, сәнгать осталары, район үзешчәннәре катнашты. Кунакка башка район – Балтач, Мамадыш, Саба, Лениногорск, Әтнә, Мөслим җырчылары Айгөл Бариева, Искәндәр Биктаһиров, Люция Мусина, Ришат Шәйхетдинов, Алсу Әбелханова, Алинә һәм Азат Кәримовлар килгән иде.

– Моны безнекеләр – арчалылар гына булдыра! Башка бер генә район якташлары да ике көн рәттән искиткеч тамаша күрсәтми! Бу концертны күрми калырга бернічек тә ярамый иде. Рәхәтләнеп, көтеп алып, бик зур теләк белән җыелдык бирегә, – дип горурлана Арчадан килгән бер төркем тамашачы-кунаклар.

Хәер, туган яклары, якташлары белән ихластан горурлану хисе бирегә килгән һәр кешенең күз карашыннан ук сизелә иде. Горурланырсың да, күп кенә танылган, абруйлы, талантлы шәхесләрнең туган ягы бит ул Арча!

Якташларын сәламләргә район хакимияте башлыгы Илшат Нуриев та килгән иде.

– Менә инде өченче ел рәттән бу очрашуны көтеп алабыз, ярагып киләбез. Бер очрашу – бер гомер, диләр. Бирегә сезне күрү, фикерләрегезне ишетү, кайткач, шул теләкләрне тормышка ашырып яшәү тормышыбызга дәрт өсти. Арчада бик күп эшләр эшләнә. 2,5 ел эчендә икенче мәктәп сафка басып килә, узган ел дүрт балалар бакчасы төзегән булсак, быел тагын икене салабыз, ике авылда мәдәният йорты, ике ФАП, ветеринарлар өчен ике йорт булдырдык, җиде авылга асфальт юл салынды, быел тагын дүрт авыл планда каралган. Арча – иң зур авыл хуҗалыгы районнарының берсе, якташларыбызның дәүләт икмәгенә керткән өлеше шулай ук зур. Киләчәктә дә сезнең белән аралашып, дус булып яшәргә насыйп булсын, – диде ул.

– Арчаның үзендә генә түгел, Казанга чыгып киткән якташларыбыз да бик зур эшләр эшли. Безнең районнан чыккан өч министрыбыз, генералларыбыз, дәүләт эшлеклеләребез бар. Аларның һәрберсе Тукайның йөзенә кызыллык китермичә, тырышып эшли. Арчалылар – бердәм, нурлы халык. Ике көнлек концертыбызга килергә дә теләк белдерүчеләр шулкадәр күп булды, хәтта өстәмә рәвештә урындыклар куеп, күбрәк кешене кертү мөмкинлеген тудырдык, – диде «Арча якташлыгы» җәмгыяте рәисе, Кәрим Тинчурин театры директоры Фәнис Мөсәгыйтов.

Аның сүзләре буенча, быел Президент якташлыкларга грант бирү указын чыгарган. Татарстан муниципаль берәмлекләр шурасы рәисе Минсәгыйть Шакиров тәкъдим итүе белән, барлык якташлыкларның координацион советы төзелгән.

– Моннан соң барлык якташлыклар бер-березбезне белеп, аралашып яшәрбез дип өметләнәм. Һәм әлеге концерт та шуңа беренче адымнар булсын иде, – дигән теләкләрен җиткерде Фәнис әфәнде.

«Ак калфак» – ике арада күпер

Камал театрында Илдар Юзеев әсәре буенча баш режиссер Фәрит Бикчәнтәев куйган премьера тәкъдим ителде.

ПРЕМЬЕРА

Люция ХӘБИБУЛЛИНА

Спектакль телевизион күперне хәтерләтә. Америкада яшәүче татарлар белән Казандагы милләттәшләрне уйнаган артистлар ике якка тезелеп утырганнар. Журналистлар – Татарстанның халык артистлары Люция Хәмитова (Сафия) һәм Раушания Юкачева (Клара) әйтерсең тамашачыны да әлеге телевизион күпердә катнаштыра.

Ике якта да – милләтебезнең танылган шәхесләре. Төрле сәбәпләр аркасында Америкада яшәүчеләр арасында төрле һөнәр ияләре бар. Казан татарларының кайберләре аларның чит илдә гомер итүен гаепли. «Илдәшләреңне авыр хәлдә калдырып китү – җинаять. Чит илдә солтан булганчы, үз илеңдә олтан бул», – ди Шәмсия Ишмуллина. Аның үз улы да Америкада әлеге телекүпердә катнаша. Татарстанның халык, Россиянең халык артисты Рузия Мотыйгуллина ананың кичерешләрен үзәк өзгеч итеп гәүдәләндерә. Тик аның улы Жак (Татарстанның халык, Россиянең атказанган артисты Илдус Әхмәтҗанов) Америкага киткәч, үзенең Габделхак исеменнән ваз кичеп яшәгән. Ул гомер буе ак калфакны саклый. Хатыны, француз кызы Катрин Люсильдә (Татарстанның һәм Россиянең халык артисты Алсу Гайнуллина) дә татар халкына карата мәхәббәт тәрбияли.

Илдар Мөхәммәтҗанов фотосы

Заманында сугышта очрашкан Исмай (Татарстанның һәм Россиянең халык артисты Әзһәр Шакиров) белән Майк та (Татарстанның халык, Россиянең атказанган артисты Айдар Хафизов) телекүпер аша бер-берсен таный. Гомумән, һәркайсының бер-берсен тану күренешләре үзәкләрне өзәрлек. Фән кандидаты Регинаның да яратып йөргән егете Тайфур Америкага китеп барган. Рәссам булачак аны безнең илдә танымаганнар. Туры сүзле, горур Тайфур образын Татарстанның халык артисты Искәндәр Хәйруллин оста итеп чагылдыра. «Ак калфакны төшердек кулдан. Бердәмлек юк бит бездә. Кем генә җимермәде безнең күперләрне», – ди ул. Регина Тайфурны танып ала. Татарстанның халык артисты Венера Шакирова кызның хисләрен белдергән мизгелне тетрәндерерлек итеп башкара.

Көрәшче Иванов Павел үзенең җор телле булуы белән аерылып тора. Ул нинди генә авыр чорларда да үз иленнән китмәгән. Татарстанның халык, Россиянең атказанган артисты Наил Дунаев бу рольдә нәкъ үзен уйный кебек.

Америкада яшәүче милләттәшләр үзебезнең илгә карата төрле фикердә. Ратмир (Татарстанның халык артисты Илдус Габдрахманов), Татарстанда югары сәнгатьне аңламыйлар, дип саный. Ул – биюе белән Парижны яулаган шәхес. Гөлнур ханым (Татарстанның атказанган артисты Мәрьям Йосыпова) Казанга кунакка килгән җиреннән татарларның русча сөйләшүенә гаҗәпләнеп киткән. Зөбәйдә Прайс (Алинә Мөдәрисова) – Америкадагы татарларның яшь буын вәкиле. Ул татар телен белми, әмма татар моңын, җырын әбисе белән әнисеннән отып калган. Аның җырында туган илне сагыну, җирсү хисләре яңгырый.

Спектакльне караганда милләттәшләр язмышы өчен борчылып, моңсуланып та утырасың. Ирексездән, күздән яшьләр дә тәгәри. Бүгенге көндә актуаль булган күренешләр белән очрашасың. Спектакльдә өлкән буын артистлар уйнавы аны тагын бер баскычка күтәрә.

Шәһри Казан

ИНДЕКСЛАР
П2395 (3 тапкыр чыга)
П2430 (пәнҗешәмбе саны)
П2419 (оешмалар өчен)

www.shahrikazan.com

ГАМӘЛГӘ КУЮЧЫ (НӘШЕР ИТҮЧЕ) – «ТАТМЕДИА» АҖ
«ТАТМЕДИА» АҖ ФИЛИАЛЫ ҖИТӘКЧЕСЕ –
БАШ МӨХӘРРИР ГӨЛНАРА ИЛЬЯС кызы САБИРОВА.

© Газетада басылган язмаларны файдалану, шулай ук өзекләр китерү өчен, «ШК» редакциясеннән язмача рөхсәт алу мәҗбүри. Редакциянең фикере авторларның фикере белән аваздаш булмаска да мөмкин. Редакциянең рәсми оешмаларда юллаучы булып йөрү мөмкинлеге юк. Кульязмалар рецензияләнми һәм кире кайтарылмый. Реклама һәм игъланнардагы мәгълүматларның дөреслеге өчен аны бирүчеләр үзләре җаваплы.

РЕКЛАМА ХЕЗМӘТЕ
Тел: (843) 562-50-12,

ХАТЛАР БҮЛЕГЕ
Тел: (843) 562-50-03,
E-mail: shahri-kazan@tatmedia.com

НӘШРИЯТ
«Татмедиа» АҖ
420097, Казан, Академия ур., 2

16+

Сатудагы бәясе ирекле

Бу санның тиражы – 1642. Гомуми тираж – 6179.
Республика матбугат һәм массакүләм коммуникацияләр агентлыгы ярдәме белән чыгарыла.
Заказ 699. Газета Элемтә, мәгълүмати технологияләр һәм массакүләм коммуникацияләр өлкәсендә күзәтчелек итү буенча Федераль хезмәттә (Роскомнадзор) 2012 елның 27 августында ПИ №ФС77-50970 нче теркәлү таныклыгы алды. Газета атнага 3 тапкыр – сишәмбе, пәнҗешәмбе һәм җомга көннәрендә чыга. График буенча бу санга 17 сәгатьтә кул куелырга тиеш. Кул куелды – 17 сәгатьтә.

РЕДАКЦИЯ АДРЕСЫ
420066, Казан,
Чистай ур., 5 нче йорт
Тел.: (843) 562-50-12,
факс: (843) 562-50-07

БАСМАХАНӘ
420066, Казан, Декабристлар ур., 2 нче йорт.
«ТАТМЕДИА» АҖ филиалы.
«Идел-Пресс» полиграфия-нәшрият комплексы